**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 апреленнән № 9-58

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмә хакында» 2011 елның 20 декабрендәге 9-75 номерлы карарына үзгәрештәр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 20.12.2011 елның 20 декабрендәге 9-75 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 37-213 номерлы, 2016 елның 28 июнендәге 15-67 номерлы, 2019 елның 5 мартындагы 47-270 номерлы, 2019 елның 18 апрелендәге 48-283 номерлы, 2021 елның 24 ноябрендәге 15-119 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Контроль-хисап паласы рәисенең вазифасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш. Контроль-хисап паласы рәиесе «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне әлеге федераль законнарда билгеләнгән очракларда тапшырырга тиеш. Әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.»;

1.2. Нигезләмәнең 10 статьясындагы 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар уздыру өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс контроле стандартлары Россия Федерациясенең Хисап палатасы раслаган гомуми таләпләр нигезендә Контроль-хисап палатасы тарафыннан раслана.»;

1.3. Нигезләмәнең 21 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларын матди һәм социаль тәэминат итү

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына акчалата тәэмин итү (бүләкләү), еллык түләүле отпусклар (төп һәм өстәмә), һөнәри үсеш, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу, шулай ук муниципаль берәмлекнең муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән матди һәм социаль тәэминатның башка чаралары (шул исәптән медицина һәм шифаханә-курорт тәэминаты, көнкүреш, транспорт һәм хезмәт күрсәтүнең башка төрләре буенча) гарантияләнә.

2. Район Контроль-хисап палатасы рәисен матди һәм социаль тәэмин итү чаралары «Россия Федерациясе субъектларының, федераль территорияләрнең һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский